**<u>Татар халык җыры</u>**

## Бөрлегәнем — бер генәм

Бакчаларда чәчәк ата
Син утырткан бөрлегән.
Ул да сине күтә сыман,
Ник килмисең, бер генәм?

Бөрлегәнем, бөрлегән,
Сагындырдың бер генәм.

Бүген төнлә төшләремдә
Сине күрдем, бер генәм.
Син тал, имеш, ә мин, җаным,
Гүя кара бөрлегән.

Бөрлегәнем, бөрлегән,
Бик сагындым бер генәм.

Бөрлегәндәй күзләреңне
Бик сагындым, бер генәм;
Сөям, дигән сүзләреңне
Кабатлыйм мин җыр белән.

Бөрлегәнем, бөрлегән,
Син бит минем бер генәм.